ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.01.2021 г.Лениногорск №27

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау фондын формалаштыру ысулын сайлау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 170 статьясының 7 пункты нигезендә һәм «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге №52-ТРЗ Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Күпфатирлы йортларга карата капиталь ремонт фондын формалаштыруны (кушымта нигезендә), биналарның милекчеләре тарафыннан капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы сайланмаган һәм (яки) алар сайлаган ысул Россия Федерациясе Торак кодексы белән билгеләнгән тәртиптә тормышка ашырылмаган очракта, региональ оператор — «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы Фонды» коммерцияле булмаган оешмасы счетында билгеләргә.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Карар имзаланган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Ф.М. Фәрхетдинов
5-76-90

Кушымта

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән
«18» гыйнвар 2021 ел № 27

Капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы сайланмаган күпфатирлы йортлар исемлеге

| №п/п | Район | Күпфатирлы йорт адресы (торак пункт,урам,йорт) |
|---|---|---|
| 1. | Лениногорск | Лениногорск ш., Куйбышев ур., 26 йорт |
| 2. | Лениногорск | Лениногорск, Горький ур., 35А йорт |
| 3. | Лениногорск | Лениногорск, Краснокамская, ур., 3 йорт |
| | **Барлыгы:** | **3 күпфатирлы йорт** |

___________________________________